| ГЛАВА СОВЕТА ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2021 ел Хуҗа Хәсән авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең
Кушкүл торак пунктында гражданнар
җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2021 елның 23 ноябренә 14 сәг 00 минутка Кушкүл ав., 1 Май ур., 11 йорт адресы буенча урнашкан Кушкүл авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегең Кушкүл торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең Кушкүл авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- җирлек торак пунктлары территорияләрен чүплекләрдән чистарту;
- материаллар сатып алып, зиратка ярдәмче бина урнаштыру
- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Яңа короновирус (COVID-19) йогышы белән авыру очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар – эпидемиягә каршы чараларның үтәлешен тәэмин итәргә Хуҗа Хәсән авыл җирлеге территориясендә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башлыгы С.П.Матвеева